МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ**

29.12.2017

**БОЕРЫК**

07-142

Башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап тапшыру хакында

“Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым средстволарын җәлеп итү нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл кылуга башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында” 22.11.2013 ел, № 909 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, б о е р ы к б и р ә м:

1.Башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап тапшыру тәртибен (кушымта итеп бирелә) расларга

2.“Башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап тапшыру хакында” 18.08.2014 ел, № 07-80 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары О.А.Кисаповага йөкләргә.

Министр Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы
Финанс министрлыгының
29.12.2017 № 07-142_боерыгы белән расланды

Башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап тапшыру
Тәртибе

1. Бу Тәртип  муниципаль районнарның (шәһәр округлары) җирле үзидарә органнары тарафыннан “Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым средстволарын җәлеп итү нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл кылуга башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында” 22.11.2013 ел, № 909 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә бирелә торган башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисапны (алга таба – хисап) тапшыру кагыйдәләрен, срокларын һәм формаларын билгели.
2. Муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары тиешле муниципаль район составына керүче, үзенә башка бюджетара трансфертлар бирелгән һәр муниципаль берәмлек буенча хисап тапшыра.
3.  Муниципаль районнарның (шәһәр округлары) җирле үзидарә органнары хисапны кәгазьдә (бер үк вакытта «БАРС Web-Своды» программасында эшләнгән электрон күчермәсе белән) тапшыра. Шул ук вакытта хисапның төп нөсхәсе һәм күчермәсе эчтәлеге ягыннан бер үк төрле булырга тиеш. Хисап, бу Тәртипкә кушымта нигезендәге форма буенча, хисап финанс елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына төзелә һәм хисап финанс елыннан соң килүче елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча тапшырыла.
4. Кәгазьдәге хисапка эш башкаручы (вазыйфасын, элемтәгә керү өчен телефон номерын күрсәтеп), муниципаль берәмлекнең финанс органы җитәкчесе, муниципаль берәмлек башлыгы имза сала (тулы имзасы белән), имза салу датасын күрсәтеп, һәм хисап әлеге органының мөхере белән раслана.

Татарстан Республикасы Финанс
министрлыгының 29.12.2017 № 07-142
боерыгы белән расланган
Башка бюджетара трансфертлардан файдалану
турында хисап тапшыру тәртибенә кушымта

Форма

20___ елның 1 гыйнварына
бюджет чыгымнары турында хисап _______________________________________________________
(муниципаль берәмлек атамасы), финанс белән тәэмин итү чыганагы булып "Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым средстволарын җәлеп итү нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл кылуга башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында" 22.11.2013 ел, № 909 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә бирелгән башка бюджетара трансфертлар торган

| | |
|---|---|
| Муниципаль берәмлекнең бюджеты чыгымнары турында хисапны булдыручы финанс органы атамасы | |

Үлчәү берәмлеге: сум.

1. Финанс белән тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар торган средстволар хәрәкәте

| Күрсәткеч атамасы | Сумма |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Хисап елы башына калдык, барлыгы | |
| шул исәптән:<br>ихтыяҗы расланган | |
| Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле | |
| Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган средстволар, барлыгы | |
| шул исәптән:<br>ихтыяҗы расланган, ел башына калдык | |
| агымдагы елга күздә тотылган | |
| Башка бюджетара трансфертлар средстволары хисабына муниципаль берәмлек тоткан чыгым (касса чыгымы) | |
| шул исәптән:<br>кире кайтарылган узган еллар калдыклары средстволары хисабына тотылган | |
| агымдагы ел өчен күздә тотылган средстволар хисабына тотылган | |
| Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылган средстволар, барлыгы | |
| шул исәптән:<br>файдаланылмый калган средстволар калдыгы | |
| ихтыяҗы булмаган агымдагы ел калдыгы | |
| Татарстан Республикасы бюджетына түләтелгән | |
| Хисап елы азагына калдык, барлыгы | |
| шул исәптән:<br>чираттагы финанс елына ихтыяҗы расланган | |
| Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле | |

2.Гражданнарның үзара салым средстволарын җәлеп итү нигезендә, башка бюджетара трансфертлар хисабына, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл кылу буенча чараларны үтәү турында мәгълүматлар

Үлчәү берәмлеге: сум.

| № п/п | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең коды* | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең атамасы | Чара | Касса чыгымы, барлыгы | Шул исәптән: | | | Гражданнарның үзара салымы средстволары хисабына касса чыгымы – барлыгы | Шул исәптән: | | | Татарстан Республикасы бюджеты средстволары хисабына касса чыгымы – барлыгы | Шул исәптән: | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | хисап финанс елыннан 2 ел алдан килгән ел өчен | хисап финанс елыннан алда килгән ел өчен | хисап финанс елы өчен | | хисап финанс елыннан 2 ел алдан килгән ел өчен | хисап финанс елыннан алда килгән ел өчен | хисап финанс елы өчен | | хисап финанс елыннан 2 ел алдан килгән ел өчен | хисап финанс елыннан алда килгән ел өчен | хисап финанс елы өчен |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 (9+13) | 6 (10+14) | 7 (11+15) | 8 (12+16) | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 |
| | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | |
| Барлыгы | | | | | | | | | | | | | | | |

*- “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 14,15,16 статьяларындагы 1 өлеше пунктының номерына туры килә

Муниципаль берәмлек
башлыгы ______________/_________________________/
(имза) (тулы имза)

М.У.

Муниципаль берәмлекнең финанс органы
җитәкчесе ______________/_________________________/
(имза) (тулы имза)

Эш башкаручы ____________ __________ _______________________ __________________
(вазыйфасы) (имзасы) (тулы имзасы) (код белән телефон номеры)

"__" ______________ 20__ ел